ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЛАР

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2016 елның 17 декабре**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 3623**

Татарстан Республикасы Зеленодольск ш. Рогачёв урамы 18 нче йортның техник торышын кабат тикшерү нәтиҗәләре турында.

Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Рогачёв урамы, 8 йорт адресы буенча урнашкан йортның тузу һәм яшәү өчен яраклы булу дәрәҗәсен кабат тикшерү турында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 15 декабрендәге ведомствоара комиссиясе актын һәм бәяләмәсен карап, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре, Рогачев урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының ведомствоара комиссиясенең 21.11.2011 №93 акты һәм нәтиҗәсе нигезендә авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы торак йортның яшәү өчен яраксыз булуын кабат расларга.
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең авария хәлендәге торактан гражданнарны күчерү программасын гамәлгә ашыру буенча урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин